Муниципаль бюджет гомумбелем бирү учреждениясе “Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре 8нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе”

« Каралды » методик берләшмә утырышында Методик берләшмә җитәкчесе _____________ /Мазитова Л.К./ Протокол № 1 « 27 » август 2018 ел	«Килешенде » Укыту эшләре буенча директор урынбасары_________ /Григорьева Г.Д./ « 28 » август 2018 ел	« Раслыйм» Мәктәп директоры _____________ / Граф А.А./ Приказ № 253 « 29 » август 2018ел

1 нче квалификацион категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Хатыйпова Фәридә Җамалетдин кызының
рус мәктәбенең (5-9) сыйныфта укучы татар балаларына туган тел (әдәбият) дәресеннән эш программасы

база дәрәҗәсе

“29” август 2018 нче ел
№1 беркетмә белән педагогик
киңәшмә утырышында кабул ителде.

2018-2019 нчы уку елы

ТУГАН ТЕЛ ӘДӘБИЯТЫНА ӨЙРӘТҮНЕҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр

- шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү, күпмилләтле илебезгә карата ярату хисләре, татар әдәбиятына һәм башка халыклар әдәбиятына, мәдәниятенә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү;
- төрле мәгълүмат чараларын танып-белү һәм аралашу мәсьәләсен хәл иткәндә (сүзлекләр, энциклопедия, Интернет ресурслар һәм башкаларны) куллану;
- активлыкка, мөстәкыйль фикер йөртүгә, акыл һәм рухи эшчәнлеккә өйрәтү, шәхес буларак формалашуны дәвам итү;
- үзең белән идарә итүгә юнәлдерелгән белем һәм күнекмәләрне тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү, тормышта үз урыныңны күзаллый башлау;
- милли горурлык, гражданлык хисләре формалаштыру, әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү.

Метапредмет нәтиҗәләре

“Әдәбият” курсын өйрәнүнең метапредмет нәтиҗәләре булып, универсаль уку-укыту гамәлләре формалаштыру санала (УУГ).

Регулятив УУГ (РУУГ):

- мөстәкыйль рәвештә дәреснең проблемасын (тема) һәм максатларын формалаштыру;
- проблеманы аңлый белү, гипотеза чыгару, материалны төзү, үз фикереңне раслау өчен дәлилләр сайлый белү, телдән (диалогик, монологик) һәм язма сөйләмдә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен аерып алу, нәтиҗәләрне формалаштыру;
- максатка ирешү юлларын билгеләү;
- уку проблемасын чишү өчен план төзү;
- шушы план нигезендә эш оештыру, үз эшчәнлегенең максатка ирешүдә ни дәрәҗәдә нәтиҗәле булуын күзәтү;
- укытучы бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларын бәяләү.

Танып белү УУГ (ТБУУГ):

- укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә оештыра белүе, бәяләү, үзенең кызыксынучанлык өлкәсен билгеләве;
- мөстәкыйль рәвештә төрле текстларны укый белү (төп текст, астөшермә һәм башкалар), өстәмә материалларны таба һәм тиешле урында куллана белү;
- укуның төрле формаларыннан файдалану (аңлап уку, өстән-өстән, эчтәлекне аңлап);
- төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белү;үзенә кирәкле мәгълүматны төрле формада бирелгән чыганаклардан туплау (тулы текст, өзек, иллюстрация, схема);
- бер мәгълүматны икенче төрле итеп үзгәртә алу (план төзү, таблица, схема);
- укылган әсәрнең эчтәлеген (яки ишеткәнне), текстка якын итеп, кыскача сайлап сөйли белү;
- әдәбиятны музыка, рәсем сәнгате белән бәйләп, сүз сәнгатенең кыйммәтен күрсәтү, матурлыкны танырга өйрәтү;әдәбиятны тел белеме белән бәйләп, әдәби әсәр теленең үзенчәлекләрен, әсәр стилен җиткерү;
- татар әдәбиятын рус әдәбияты, башка халыклар әдәбиятлары белән бәйләп укытып, әдәбиятлар арасындагы уртак проблемаларны, уртак кыйммәтләрне күрсәтү аша, дөнья культурасы белән танышу;

- сүзлекләр, белешмә материаллардан файдалану;
- бәхәсләшү, үз фикерен дәлилләү, анализ ясау, йомгаклау;
- әдәбиятны тарих, җәмгыять белеме, экология предметлары белән бәйләп, дөнья яшәү, табигать, кешелек җәмгыяте турында күзаллау формалаштыру.

Коммуникатив УУГ (КУУГ):
- төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү;
- үз фикерен тексттан өземтәләр китереп дәлилли белү;
- бер фикер кабул иткәнче, төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау;
- күмәк эш вактында, бигрәк тә фикер агышлары төрле булганда, бер фикергә килә белү;
- укылган, тыңланган әсәрләр буенча сораулар бирә алу;
- үз эшен контрольдә тоту, иптәшләренә ярдәм итү;
- коммуникатив күнекмәләрнең кеше тормышындагы ролен билгеләү;
- үз фикерләрен телдән һәм язмача җиткерә белү;
- башкаларны тыңлый, кирәк булганда үз фикерләрен үзгәртә алу;
- иптәшләре каршында төрле темаларга чыгыш ясау, бергәләп эшләгәндә бердәм карар кабул итә белү;
- текст буенча сораулар куя белү.

Татар әдәбияты укытуның предмет нәтиҗәләре
- сүз сәнгатенең образлы табигатен тою;
- өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген аңлау;
- классик әдипләрнең (К.Насыйри, Г.Тукай, Г.Ибраһимов, М.Җәлил һ.б.) биографик белешмәләре белән танышу;
- өйрәнгән әдәби-теоретик төшенчәләрне истә калдыру;
- әдәби текстны кабул итү һәм анализлау;
- әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару, укыган буенча тезислар һәм план төзү;
- әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклау;
- укыган әсәрнең темасын, проблемасын билгеләү;
- геройларга характеристика бирү;әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру;
- сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен ачу;
- кабатлап сөйләүнең төрләреннән файдалану;
- өйрәнелгән әсәргә бәйле рәвештә телдән һәм язмача фикер белдерү;укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерне дәлилли белү;
- татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү;
- эстетик зәвыкка туры килә торган әдәби әсәрләрне сайлау һәм аларны бәяләү;

- аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәкле мәгълүматны белешмә әдәбият, вакытлы матбугат, Интернет чаралары һәм башкалар аша эзләү.

УКУ ПРЕДМЕТЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

Федераль базис укыту планында каралганча, 5 нче- 9нчы сыйныфларда туган тел әдәбиятын өйрәнүгә атнасына 1 сәгать исәбеннән елга 35 сәгать бирелә, бу Татарстан Республикасының базис укыту планына туры килә.Планны “Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары”на (Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова, Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2018) нигезләнеп төзедем.

Укучылар урта сыйныфларда халык авыз иҗаты әсәрләренең төрле жанрларын өйрәнә башлап, борынгы, XVII, XVIII, XIX, XX йөз әдәбиятларыннан иң яхшы әсәрләр белән, язучының тормыш юлы һәм иҗаты белән танышалар.

5 -9нчы сыйныфта алдагы сыйныфта укыганнарга нәтиҗә ясала, әдипләрнең биографияләре тирәнтен өйрәнелә, яңа темалар, проблемалар белән таныштырыла, укыганны тирәнрәк аңларга, төрле белешмә әдәбиятны кулланырга өйрәтелә. Сөйләм күнекмәләрен камилләштерүгә, бәйләнешле сөйләмнәрен, иҗади эш күнекмәләрен ныгытуга махсус рубрикалар бирелә.

Программаның эчтәлеге түбәндәге бүлекләрдән тора һәм әлеге бүлекләр буенча үтәлергә тиешле минимумны чагылдыра.

5НЧЕ СЫЙНЫФ

Программа эчтәлеге (5 нче сыйныф)

№	Бүлекләр	Сәгать саны	Темага караган төп төшенчәләр
1	Халык авыз иҗаты	8	Фольклор – күмәк халык авыз иҗаты. Фольклорның кече жанрлары. Балалар фольклоры (табышмак, такмак, санамыш, мәсәл һ.б.) турында кабатлау. Бишек җырлары (халык авыз иҗаты белән беррәттән, авторлар иҗат иткән бишек җырларын да өйрәнү). Әдәбият теориясе. Халык авыз иҗаты. Халык авыз иҗаты буларак әкиятләр. Тылсымлы, хайваннар турындагы, тормыш-көнкүреш әкиятләре. Әкият геройлары үрнәгендә шәфкатьлелек, миһербанлылык тәрбияләү. “Ак байтал” – тылсымлы әкият. Ат турында мәкалләр. Атка мәдхия. Тылсымлы әкиятләрнең поэтикасы. Тылсымлы әкиятләрдә фантастик элементлар. “Үги кыз” – тормыш-көнкүреш әкияте. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәт. Яхшылыгыңның да, начарлыгыңның да үзеңә кире кайтуы. Бумеранг принцибы.Кыерсытылган ятимнең, яхшылыкның җиңеп чыгуы, шәфкатьле, миһербанлы булуның җимешләрен татуы. “Хәйләкәр төлке” – хайваннар турындагы әкият. “Солдат боткасы”, “Өч каләм”, “Камыр батыр”, “Кәтән Иваныч” әкиятләренең кайсы төргә керүен һәм нинди билгеләре буенча төркемләнүен ачыклау. Әдәбият теориясе. Әкият. Әкият төрләре. Әкиятнең төзелеше. Даими эпитетлар. Гипербола турында төшенчә. Чагыштырулар. Кабатлаулар. Инверсия. Әкияттә башлам, бетем, кульминаия, чишелеш, төенләнеш, үстерелеш элементлары. Халык әкиятенең вариативлыгы. Әкият геройлары. Ярдәмче геройлар.
2.	Халык иҗаты белән рухланып	1	Кешелеклелек, миһербанлы , тәрбияле, намуслы булу. Әхлак мәсьәләләрен яктырткан әсәрләр. Халык иҗаты әсәрләренә таянып, язучылар иҗат иткән мәсәлләр, Г.Тукай һәм Ә.Исхак, Г.Тукай һәм И.Крылов, Г.Тукай һәм Г.Шамуков язган исемдәш мәсәлләр. Уртак һәм аермалы яклары. Мәсәлләрне сәнгаьле уку. Әдәбият теориясе. Мәсәл жанры, читләтеп әйтү, сюжеты. Мәсәлләрдә хикәяләү, мораль. Киная. Аллегория. Мәсәл төзелеше. Бу жанрда иҗат итүчеләр.
3.	Хәзинә. Борынгы әдәбиятыбыз үрнәкләре.	1	Кол Гали турында белешмә. Безнең көннәргә кадәр килеп җиткән данлыклы “Кыйссаи Йосыф” әсәре турында. Поэмадан өзек уку. Әсәрнең сюжеты. Поэманы өйрәнгән галимнәр турында белешмә. Әлеге поэманың бик күп шагыйрьләргә “шигъри азык” бирүе. Шәүкәт Галиевның Кол Галигә багышланган шигыре.
4.	Казан ханлыгы әдәбияты үрнәкләре.	1	Мөхәммәдьяр турында белешмә. “Нуры содур” поэмасыннан өзек (шигъри хикәят) уку. Хикәятнең мәгънәсе: игелекле эш-гамәлләр һич тә юкка чыкмый, ә бәлки артыгы белән кире үзеңә кайта.
5.	XIX йөз әдәбияты үрнәкләре.	2	Каюм Насыйри, тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру. “Патша белән карт”, “Бай һәм хезмәтче”, “Аңгыралык бәласе” әсәрләренең халык авыз иҗатына нигезләнеп язылуы. “Әбүгалисина”. Белем алуның әһәмияте. Күңеле яхшылыкта булып, халыкка ярдәм итәргә теләгән Әбүгалисина һәм игезәге Әбелхарисның белем алырга омтылышлары. Тормыш юлларының аерылу сәбәпләре. Каюм Насыйри музее.
6.	XX йөз башы татар әдәбияты	3	Габдулла Тукай. Шагыйрьнең тормыш юлы турында кыскача белешмә. Башлангыч сыйныфларда шагыйрь турында өйрәнгәннәрне киңәйтү. “Су анасы”, “Эш беткәч уйнарга ярый” әсәрләреТукайның бала психологиясен сурәтләве, балаларга белем һәм тәрбия бирүгә мөнәсәбәте. Бари Рәхмәтнең “Эш

6 нчы сыйныф **Программа эчтәлеге (6нчы сыйныф)**

№	Бүлекләр	Сәгать саны	Темага караган төп төшенчәләр
1	Татар халык авыз иҗаты	9	Фольклор – күмәк халык авыз иҗаты. Фольклорның кече жанрлары. Җырлар һәм аларның төрләрен аера белү **Йола җырлары**. (“Сөмбелә җыры”) **Тарихи җырлар**. (“Герман көе”) **Лирик җырлар**. Озын җырлар.(“Иске кара урман”). Кыска җырлар.Такмак. **Уен-бию җырлары** (“Кәрия-Зәкәрия”) **Милли уен кораллары** **Көе халыкныкы булган җырларГ.Тукай “Туган тел”** Алмаз Монасыйпов .Г.Тукай “Туган авыл”
2.	Кадерле син,кеше туганым	11	Кешелеклелек, миһербанлы , тәрбияле, намуслы булу. Туган як, әхлак мәсьәләләрен яктырткан әсәрләр. Н,Исәнбәт “Өч матур сүз”.”Туган ил” **Мәҗит Гафури.** Тормыш юлы һәм иҗаты.”Әтәч белән Сандугач” мәсәле. Г,Шамуков”Арыслан белән Куян”.И Крылов “Ат белән эт” мәсәлләре белән танышу **Габдулла Тукай.** Шагыйрьнең тормыш юлы турында кыскача белешмә. Башлангыч сыйныфларда шагыйрь турында өйрәнгәннәрне киңәйтү. “Туган авыл” ,“Шүрәле” әсәрләре. Тукайның бала психологиясен сурәтләве, балаларга белем һәм тәрбия бирүгә мөнәсәбәте. Ф.Яруллин.“**Шүрәле” балеты – татар музыка сәнгатенең йөзек кашы.** **Әдәбият теориясе.** Опера. Балет. Либретто. **М.Җәлил Тормыш юлы.”Чәчәкләр”,”Тик булса иде ирек”шигырьләре белән танышу,анализлау.ӘЕники “Туган туфрак” әсәрендәге язучының фикерен ачыклау**
3.	Энҗе карлар явып үткән	3	**БСҮ “Кышкы матурлык” темасына хикәя төзеп сөйләү.** **Г,Ибраһимов Томыш юлы белән танышу.”Кар ява” хикәясен уку,анализлау** **Т.Миңнуллин “Акбай белән Кыш бабай” пьесасын рольләргә бүлеп уку**
4.	Акыл-тузмас кием,белем-кипмәс кое	7	К,Насыйри тормыш юлы белән танышу.”Әбугалисина “ әсәрен уку,анализлау Г.Сабитов “Чүкеч “ әсәре белән танышу,язучының фикерен ачыкла А.Алиш “Әни ялга киткәч” хикәясен уку,аналарга хөрмәт хисләре тәрбияләү Ф,Яруллин “Кояштагы тап” хикәясен уку,язучының фикерен ачыклау. “Тугры дус” шигырендә тугры дус төшенчәсе Г.Зәйнәшева “Кем булырга”һөнәр темасын ачыклау
5.	Ил өстендә дустың булсын	4	Дәрдемәнд “Ике туган”. Темасын һәм исемен ачыклау. Әсәрдәге геройның эчке дөньясын ачу. Әсәрнең эчтәлеген сөйләү, төп образга характеристика бирү. **Әдәби тәрҗемә** турында сөйләшү. . “ **Һади Такташ** турында белешмә. Һ.Такташ тормышындагы һәм иҗатындагы үзенчәлекләр белән танышу. Аның Тукай шигъриятендәге зур традицияләрне дәвам иттерүче новатор шагыйрь булуын аңлатырга. “Мокамай” шигыре. “ Әсәрнең сюжеты. Шигырьгә тулы анализ ясау, автор фикерен билгеләү. **Э Шәрифуллина “Дуслык,чын дуслык!**

7 нче сыйныф **Программа эчтәлеге (7 нче сыйныф)**

№п/п	Бүлекләр	Сәгать саны	Темага караган төп төшенчәләр
1.	**Халык аваз иҗаты**	2	Халык авыз иҗаты әсәрләре риваять, легенда, тарихи җырлар, эпо-дастан жанрлары белән танышу.Дастаннар “Идегщй” дастаны
2.	**20 йөз башы әдәбияты**	6	Г.Тукай “Милли моңнар”,”Кышкы кич” шигырьләре.Сыйныфтан тыш Г.Тукай.Мәсәлләр.Г Ибраһимов турында белешмә.Г Ибраһимов “Табигать балалары”.Һ Такташ иҗаты турында белешмә.Һ, Такташ “Ак чәчәкләр”,”Алсу “ поэмасы
3.	**Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты**	5	Г.Кутуй.Тормыш юлы,иҗаты.Г.Кутуй “Рәссам”.Сыйныфтан тыш Г.Кутуйның “Рөстәм мажаралары” .Ф.Кәрим.Тормыш юлы,иҗаты. Ф.Кәрим “બездә яздыр”.Ф.Кәрим “Сөйләр сүзләр бик күп алар”
4.	**20 йөзнең икенче яртысы**	16	Х.Туфан Тормыш юлы,иҗаты.Х. Туфан “Киек казлар”шигыре,”Кайсыгызның кулы

	әдәбияты		җылы".Г.Бәшировның тормыш юлы һәм иҗаты.Г Бәширов "Менә сиңа мә!"И.Гази.Тормыш юлы, иҗаты.И.Гази "Йолдызлы малай".Ә.Еники "кем җырлады" хикәясе.Ә Еники "Туган туфрак".С. Хәким томыш юлы,иҗаты.С. Хәким "Торыгыз,Мусалар!Н.Нәҗми тормыш юлы. "Татар теле" шигыре.Г.Зәйнәшева "Туган җирем-Татарстан".М.Мәһдиев.Тормыш юлы,иҗаты.М.Мәһдиев "без-кырык беренче ел балалары"
5.	**Хәзерге заман әдәбияты**	4	Т.Миңнуллин тормыш юлы,иҗаты.Т Миңнуллин "Монда тудык,монда үстек".Марсель Галиев иҗаты.М. Галиев "Нигез" повесте
6.	**Әдәбиятлар бәйләнеше**	2	Александр Сергеевич Пушкин, Иван Крылов мәсәлләре
7.	**Барлыгы**	35	

8 нче сыйныф **Программа эчтәлеге (8 нче сыйныф)**

№	Бүлекләр	Сәгать саны	Темага караган төп төшенчәләр
I.	Татар халык авыз иҗаты.	3	Татар халык авыз иҗаты .Бәет жанры."Сөембикә" бәете.Мөнәҗәтләр. "Ата хакы,ир хакы " мөнәҗәте.
II.	17 нче – 19 нчы гасырлар әдәбияты	3	Мәүлә Колый."Хикмәтләр". Ризаэддин Фәхретдин "Сәяхәтнәмә"
III.	XX йөз башы әдәбияты.	4	Г.Тукай. "Пар ат" шигыре. Г.Исхакый "Җан Баевич". Ш.Камал "Буранда" хикәясе.
IV.	20 – 30 нчы еллар әдәбияты	3	Г.Ибраһимов "Алмачуар" хикәясе.Ф Хөсни "Сөйләнмәгән хикәя".
V.	Тәрҗемә әсәрләр	1	А. Куприн "Олеся".И Крылов "Аккош,Чуртан һәм Кысла"

VI.	XX гасырның 50 – 60нчы еллар әдәбияты	3	Н,Дәүли “Яшәү белән үлем арасында”.Кави Нәҗми “Хәят апа”әсәре.Шәйхи Маннур “Муса”романы.Ш .Галиев “Әткәйгә хат”шигыре.
VII.	20 нче йөзнең икенче яртысында әдәбият	7	Сибгат Хәким “Җырларымда телим”.Ш Рәкыйпов “Чәчәкләр сөйли беләˮМ Мәһдиев “Кеше китә,җыры кала”.Туфан Миңнуллин “Моңлы бер җыр”.Мөдәррис Әгъләмов “Бәхет”
VIII.	80 – 90ынчы еллар әдәбияты	3	Ф.Садриев “Таң җиле”.Р.Мөхәммәдиев “Беренче умырзая”
IX	Хәзерге чор татар әдәбияты	**8**	Р.Батулла. “Бию җене кагылган егет”.Ренат Харис иҗаты. “”Ике гөл”,”Ничаклы каршылык яши”,”Туган җирем” әсәрләре.Р.Вәлиев “Дустым”.”Туган телдә дәшсәмгенә”.Э.Шәрифуллина”Читтә яшәүче татарлар җыры”
	Барлыгы	**35**	

9 нчы сыйныф **Программа эчтәлеге (9 нчы сыйныф)**

№ п / п	Бүлекләр	С/с	Темага караган төп төшенчәләр
1	Татар халык авыз иҗаты	1	Риваятьләр,легендалар “Утсыз кайный торган Казан”,”Хыянәтчегә бүләк”,”Зөһрә кыз”
2	XIX-XX нче гасыр әдәбияты	31	Ш.Камал “Буранда” хикәясе.Х.Вәлиуллин “Акчарлаклар” җыры.Гаяз Исхакый”Җан Баевич” әсәре.Һ,Такташ .Тормыш юлы.”Мокамай” шигыре.Хәсән Туфан иҗаты.”Туган тел турында җырлар”,”Кайсыгызның кулы җылы”,”Кемнәр сез” шигырьләре. Мирсәй Әмир “Агыйдел” хикәясе.Шамил Усманов “Әптери агай” хикәясе. Таҗи Гыйззәт “Изге әманәт” хикәясе.Шәриф Еникеев “Солтангәрәйнең язмышы” әсәре.Самат Шакир “Үлемнән көчлерәк”.Аяз Гыйләҗев “Җомга көн,кич белән”.Илдар Юзеев “Таныш моңнар”,”Гашыйклар тавы” поэмасы.Фәнис Яруллин “Җилкәннәр җилдә сынала” әсәре.Миргазыян Юныс “Шәмдәлләрдә генә утлар яна”.Мәдинә Маликова “Чәчкә балы”
3	Тугандаш төрки халкы әдәбияты	1	Нажар Нәҗми .Тормыш юлы.”Татар теле” шигыре.

4	Кабатлау	1	Үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау
	Барлыгы	34	Сайлап алып уку, укыганны анализлый белү, үз фикереңне дәлилләр табып исбатларга өйрәнү. Әңгәмә, сөйләү, образларга телдән бәяләмә бирү, сүзлек эше, анализ, биремнәр эшләү.

6 нчы сыйныф туган тел(әдәбият) дәресеннән календарь –тематик план

№ п\п	Бүлек №	Тема	Сәг саны	Үткәрү вакыты	
				план	факт
		1.Халык авыз иҗаты –(9 сәг.)			
1	1.1	Татар халык авыз иҗаты Мифлар	1	06.09.	
2	1.2	**Мәкальләр һәм әйтемнәр**	1	13.09.	
3	1.3	Йола һәм уеннар	1	20.09.	.
4	1.4	Тат халык җырлары“Сөмбелә”,”Көзге ачы җилләрдә” җыры	1	27.09.	
5	1.5	Уен җырлары “Кәрия-Зәкәрия”,”Әпипә”	1	4.10	

6	1.6	Көе халыкныкы булган җырлар Г,Тукай “Туган тел”	1	11.10	
7	1.7	Алмаз Монасыйпов.Г.Тукай “Туган авыл”	1	18.10.	
8	1.8	Татарстан Республикасы гимны	1	25.10.	
9	1.9	**Р.Ваһапов Тормыш юлы**	1	8.11	
		2. Кадерле син,кеше-туганым!(-11 сәг)			
10	2.1	**Н,Исәнбәт “белән Өч матур сүз”,”Туган ил”**	1	15.11	
11	2.2	**М,Гафури.”Әтәч Сандугач” мәсәле**	1	22.11	
12	2.3	Г.Шамуков “Арыслан белән Куян” И, Крылов “Ат белән эт”мәсәле		29.11	
13	2.4	Г, Тукай “Шүрәле” әкияте	1	6.12	
14	2.5	БСҮ Б Әлменов “Шүрәле “ картинасы	1	13.12	
15	2.6	**Ф,Яруллин“Шүрәле” балеты – татар музыка сәнгатенең йөзек кашы.**	1	20.12	

16	2.7	**М.Җәлил .Тормыш юлы"Чәчәкләр","Тик булса иде ирек" шиг-ре**	1	27.12	
17	2.8	Муса Җәлилнең музей-квартирасы	1	17.01	
18	2.9	**Ә.Еники "Туган туфрак"1-2 бүлек**	1	24.01	
19	2.10	Ә.Еники "Туган туфрак3-4 бүлек	1	31.01	
20	2.11	И.Юзеев "Бакчачы турында баллада"	1	7.02	
3.Энҗе карлар явып үткән..(-3 сәг)					
21	3.1	**БСҮ "Кышкы матурлык"**	1	14.02	
22	3.2	Г.Ибраһимов.Тормыш юлы,иҗаты."Кар ява" хикәясе	1	21.02	
23	3.3	**Т.Миңнуллин "Акбай белән Кыш бабай "пьесасы**	1	28.02	
4. Акыл-тузмас кием,белем-кипмәс кое-(7). сәг					

24	4.1	К.Насыйри "Әбугалисина"	1	7.03	
25	4.2	Г.Сабитов "Чүкеч"	1	14.03	
26	4.3	**А.Алиш.Тормыш юлы."Әни ялга киткәч"**	1	21.03	
27	4.4	Ф.Яруллин Тормыш юлы "Кояштагы тап" хикәясе	1	4.04	
28	4.5	Ф.Яруллин "Тугры дус" шигыре	1	11.04	
29	4.6	Г,Зәйнәшева "Кем булырга"	1	18.04	
30	4.7	С,Сәйдәшев Томыш юлы	1	**25.04**	
		5. **Ил өстендә илле дустың булсын(4 сәг)**			
31	5.1	Дәрдемәнд "Ике туган"	1	2.05	
32	5.2	ҺТакташ "Мокамай"шигыре	1	9.05	

33	5.3	Р Харис “Серле елан”хикәясе	1	16.05	
34	5.4	Еллык арадащ аттестация эше.Контроль тест	1	23.05	
6. Көлке көлә килә(1 сәг)					
35	6.1	Йомгаклау Ф,Шәфигуллин “Ике тиен акча”.”Акбай белән Карабай”	1	30.05	

Татар әдәбиятыннан белем һәм күнекмәләрне бәяләү нормалары

Язма сөйләм:

Сочинение укучыларның тормыштагы күзәтүләреннән алган тәэсирләрен язмада грамоталы һәм эзлекле бирә белү, әдәби әсәрнең эчтәлеген үз сүзләре белән образлы телдә бәйләнешле итеп яза алу мөмкинлеген тикшерү максатыннан яздырыла.

Тәкъдим ителгән темага эзлекле язылган һәм эчтәлеге тулы ачылган, 1 орфографик, 1 пунктуацион яки 2 грамматик хатасы булган эшкә "5" ле куела.

Тәкъдим ителгән темага эзлекле язылган, ләкин 2-3 эчтәлек ялгышы, 2-3 орфографик, 2-3 пунктуацион хатасы булган эшкә "4" ле куела.

Тәкъдим ителгән темага өлешчә эзлекле язылган, эчтәлеге тулысынча ачылмаган, 4-5 орфографик, 4-5 пунктуацион һәм җөмлә төзелешендә хаталары булган эшкә "3" ле куела.

Тәкъдим ителгән темага эзлекле язылмаган, эчтәлеге ачылмаган, 6 дан артык орфографик, 6 дан артык пунктуацион һәм грамматик хаталары булган эшкә "2" ле куела.

Телдән җавап бирүне тикшерү :

а) тыңлап аңлау – 0,9 минут

ә) диалогик сөйләм – 6-7 реплика

б) монологик сөйләм – 8-10 фраза

Тыңланган текстның эчтәлеге буенча сорауларга язмача җавап бирүне бәяләү.

Тыңланган текстның эчтәлеген тулаем аңлап, тәкъдим ителгән барлык сорауларга язмача дөрес җавап бирелгән, 1 орфографик хатасы яки эчтәлеккә бәйле 1 хатасы булган эшкә "5" ле куела.

Тыңланган текстның эчтәлеген тулаем аңлап, тәкъдим ителгән барлык сорауларга язмача дөрес җавап бирелгән, әмма 2-3 орфографик, 3 пунктуацион яки эчтәлеккә бәйле 2-3 хатасы булган эшкә "4" ле куела.

Тыңланган текстның эчтәлеген өлешчә аңлап, тәкъдим ителгән сорауларга төгәл дөрес җавап бирелмәгән, 5 орфо график, 5 пунктуацион яки эчтәлеккә бәйле 4-5 хатасы булган эшкә "3" ле куела.

Тыңланган текстның эчтәлеге буенча тәкъдим ителгән сорауларга бирелгән җавапларның яртысы дөрес булмаса, 6 орфо график, 6 пунктуацион яки эчтәлеккә бәйле 5 тән артык хатасы булган эшкә "2" ле куела.

Диалогик сөйләмне бәяләү

Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора алганда, әйтелеше һәм грамматик төзелеше ягыннан дөрес, эчтәлеге ягыннан эзлекле һәм тулы диалогик сөйләм төзегәндә, "5" ле куела.

Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора алганда, әмма репликаларның әйтелешендә һәм аерым сүзләрнең грамматик формаларында 2-3 хата җибәреп, эчтәлеге ягыннан эзлекле диалогик сөйләм төзегәндә, "4" ле куела.

Өстәмә сораулар ярдәмендә генә әңгәмә кора алганда, репликаларның әйтелешендә һәм сүзләрнең грамматик формаларында4-6 хата җибәреп, эчтәлеген бозып сөйләм төзегендә, "3" ле куела.

Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча диалог төзи алмаганда, "2" ле куела.

Монологик сөйләмне бәяләү

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча әйтелеше, грамматик төзелеше ягыннан дөрес һәм эчтәлеге ягыннан тулы, эзлекле булган монологик сөйләм өчен “5” ле куела.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле төзелгән, әмма аерым сүзләрнең әйтелешендә, грамматик формаларында яки җөмлә төзелешендә 2-3 хатасы булган монологик сөйләм өчен “4” ле куела.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле төзелмәгән, сүзләрнең әйтелешендә, җөмлә төзелешендә 4-7 хатасы булган монологик сөйләм өчен “3” ле куела.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән темага монолог төзи алмаганда, “2” ле куела.

Тестны бәяләү:

1 95% – 100% эшләнсә, (10 бирем) – “5 – эффектив” билгесе куела (югары дәрәҗә, тема тулысынча үзләштерелгән, укучы өйрәнелгән материалны белә, теге яки бу сүз төркеме турында тулы күзаллый);
2 81% – 94% эшләнсә, (9 бирем) – “4 – оптималь” билгесе куела (урта дәрәҗәдән югары, тема кайбер җитешсезлекләр белән үзләштерелгән);
3 50% – 80% эшләнсә, (5 – 8 бирем) – “3 – канәгатьләнерлек” билгесе куела (урта дәрәҗә, тема начар үзләштерелгән);
4 49% һәм аннан да кимрәк эшләнсә, (4 биремнән азрак) – “2 – канәгатьләнмәслек” билгесе куела (түбән дәрәҗә, тема үзләштерелмәгән).